| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |
|---|---|---|

РЕШЕНИЕ КАРАР

2022 елның «29» декабре Алабуга шәһәре № 226

**Хезмәт таләпләрен, (вазыйфаи) тәртип һәм мәнфәгатьләр конфликтын чишү буенча комиссия исемлеген раслау турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми мәсләкләре турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының "Хезмәт (вазифаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга карата таләпләр", 12.07.2018 ел, № 277 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 1 нче кушымта нигезендә хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия исемлеген расларга.
2. «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советының 2022 елның 30 июнендәге 174 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.М. Нуриев

1 нче кушымта
Татарстан Республикасы
Алабуга муниципаль районы
Советы карарына
2022 елның 29 декабре, № 226

## Хезмәт таләпләрен үтәү, (вазыйфаи) тәртип һәм мәнфәгатьләр конфликтын чишү буенча комиссия исемлеге

| | |
|---|---|
| Комиссия рәисе | Алабуга муниципаль районы башлыгы урынбасары; |
| Рәис урынбасары | Алабуга муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе; |
| Комиссия сәркатибе | Алабуга муниципаль районы советының кадрлар белән эшләү секторы мөдире; |
| Комиссия әгъзалары: | |
| | Алабуга муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе; |
| | Алабуга муниципаль районы башлыгы ярдәмчесе (Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча); |
| | "Татарстан Республикасы муниципаль районыАлабуга муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы" МКУ рәисе; |
| | Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының хокук бүлеге башлыгы; |
| | «Алабуга политехник колледжы» директоры, «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге вәкиллегенең Алабуга җирле бүлекчәсе башкарма комитеты җитәкчесе, Алабуга район Советы депутаты (килешү буенча); |
| | Алабуга муниципаль районы һөнәр берлекләренең координация советы рәисе (килештерү буенча); |
| | Алабуга "Инвалидлар җәмгыяте" территориаль иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча). |